ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**09.04.2018** **№ 794**

**2018 елга салым салынырга тиешле гражданнар кеременең һәм мөлкәт хакының иң чик күрсәткечләрен раслау турында**

Россия Федерациясе Торак кодексының 49, 51 статьяларына таянып, «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм күрсәтелгән законга кушымтада бәян ителгән Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чик күләмнәрен билгеләү методикасы, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2017 елның 20 декабрендәге 1691/пр номерлы «2018 елның беренче яртыеллыгына Россия Федерациясе буенча торак урыны гомуми мәйданының бер квадрат метры нормативы һәм 2018 елның I кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урыны гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе күрсәткечләре турында» боерыгы нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. 2018 елга гражданнарны аз керемлеләр дип тану турында карар кабул итү өчен иң чик күрсәткечләрне кушымта нигезендә расларга:

1.1. гаилә әгъзалары (ялгыз яшәүче граждан) милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күләме:

1.1.1. ялгыз яшәүче граждан өчен – 1 233 474 сум;

1.1.2. ике кешедән торган гаилә өчен – 1 569 876 сум;

1.1.3. өч кешедән торган гаилә өчен – 2 018 412 сум;

1.1.4. дүрт кешедән торган гаилә өчен – 2 691 216 сум;

1.1.5. биш кешедән торган гаилә өчен – 3 364 020 сум;

1.1.6. алты кешедән торган гаилә өчен – 4 306 824 сум;

1.1.7. җиде кешедән торган гаилә өчен – 4 709 628 сум.

1.1.8. сигез кешедән торган гаилә өчен – 5 382 432 сум.

1.2. Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең иң чик күләме:

1.2.1. ялгыз яшәүче граждан өчен – 13 050,36 сум;

1.2.2. ике кешедән торган гаилә өчен – 8 304,77 сум;

1.2.3. өч һәм күбрәк кешедән торган гаилә өчен – 7 118,38 сум.

2. Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлегенең торакны исәпкә алу һәм бүлү секторына әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктчаларында күрсәтелгән күрсәткечләрне гражданнарны торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә куйганда кулланырга.

3. Әлеге карарны ТР хокукый мәгълүматының рәсми порталында http:pravo.tatarstan.ru халыкка җиткерергә һәм Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты
җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы Д.Ф. Шәйдуллин

Кушымта

ТР Биектау муниципаль
районы башкарма
комитетының 2018 елның
«__»______ ____ номерлы
карары белән расланды

**Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм 2018 елга салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күләмнәрен билгеләү исәп-хисабы**

1. Базар бәясенең исәп-хисап күрсәткече

СЖ = НП х РС х РЦ, монда

СЖ - базар бәясенең исәп-хисап күрсәткече яки мөлкәт хакының иң чик күләме;

НП - бер әгъзага торак урын бирү нормасы;

РС - гаилә әгъзалары саны;

РЦ -2018 елның I кварталына РФ Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы тарафыннан расланган торак урыны гомуми мәйданының 1 кв. метрының уртача исәп-хисап бәясе.

| НП, кв. м | РС, кеше | РЦ 1 кв. м өчен, сум | СЖ, сум |
|---|---|---|---|
| 33 | 1 | 37 378 | 1 233 474 |
| 21 | 2 | 37 378 | 1 569 876 |
| 18 | 3 | 37 378 | 2 018 412 |
| 18 | 4 | 37 378 | 2 691 216 |
| 18 | 5 | 37 378 | 3 364 020 |
| 18 | 6 | 37 378 | 4 036 824 |
| 18 | 7 | 37 378 | 4 709 628 |
| 18 | 8 | 37 378 | 5 382 432 |

2. Гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең иң чик күләме

ПД = 0,7 х СЖ х ПС / (1-((1 + ПС) - КП)) / (0,3 х РС), монда

ПД - гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең иң чик күләме;

СЖ - социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны бирү нормасы буенча торак урыны алу өчен базар хакының исәп-хисап күрсәткече;

ПС - кредит буенча айлык процент ставкасы (9,75 / 12 = 0,8125);

КП – кредитның бөтен срогында кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (айлар саны);

РС - гаилә әгъзалары саны;

0,7 - кредит суммасы һәм фатир бәясе нисбәте;

0,3 - кредит буенча түләүнең айлык җыелма керем белән чагыштырмасы;

| Кредит суммасы һәм фатир бәясе нисбәте | СЖ, сум | ПС | КП, ай | Кредит буенча түләүнең айлык җыелма керем белән нисбәте | РС, кеше | ПД, сум |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 0,7 | 1 233 474 | 0,8125 | 180 | 0,3 | 1 | 13 050,36 |
| 0,7 | 1 569 876 | 0,8125 | 180 | 0,3 | 2 | 8 304,77 |
| 0,7 | 2 018 412 | 0,8125 | 180 | 0,3 | 3 | 7 118,38 |
| 0,7 | 2 691 216 | 0,8125 | 180 | 0,3 | 4 | 7 118,38 |
| 0,7 | 3 364 020 | 0,8125 | 180 | 0,3 | 5 | 7 118,38 |
| 0,7 | 4 036 824 | 0,8125 | 180 | 0,3 | 6 | 7 118,38 |
| 0,7 | 4 709 628 | 0,8125 | 180 | 0,3 | 7 | 7 118,38 |
| 0,7 | 5 382 432 | 0,8125 | 180 | 0,3 | 8 | 7 118,38 |